«РАСЛЫЙМ»

Татарстан Республикасы
мәгариф һәм фән министры
__________ Э.Н. Фәттахов

"6" февраль 2015 нче ел

# ТАТАР ТЕЛЕ

## Татар телендә төп гомуми белем бирү оешмаларының IX сыйныф укучыларына 2015 нче елда татар теленнән бердәм республика тесты үткәрү өчен үрнәк материалларының үзенчәлекләре (спецификация)

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы
тарафыннан әзерләнде

**Татар телендә төп гомуми белем бирү мәктәпләренең чыгарылыш сыйныф укучыларына 2015 нче елда татар теленнән бердәм республика тесты үткәрү өчен үрнәк материалларының үзенчәлекләре (спецификация)**

**1. Бердәм республика тесты үткәрү өчен үрнәк материалларының әһәмияте**

**Үрнәк** материаллары татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәпләренең IX сыйныфын тәмамлаучы укучыларның татар теленнән әзерлек дәрәҗәләрен бердәм республика тестын уздыру максатыннан бәяләүне күздә тота.

Тест нәтиҗәләре урта (тулы) мәктәпнең профильле сыйныфларына кабул итү вакытында исәпкә алынырга мөмкин.

**2. Үрнәк материаллары эчтәлеген билгели торган документлар**

Бердәм республика тесты материаллары түбәндәге документларга нигезләнеп эшләнә:

Зәкиев М.З. һ.б. Татар телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теленнән программа (5-11 нче сыйныфлар). – Казан: Мәгариф, 2011. – Б. 36-60.

Галиуллина Г.Р., Шәкүрова М.М. Татар телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләре өчен ана теленнән программа (5 – 9 нчы сыйныфлар). http://mon.tatarstan.ru/rus/file/pub/pub_263448.docx

**3. Үрнәк материалларының төзелешен һәм эчтәлеген билгеләү алымнары**

Татар теленнән бердәм республика тестының үрнәк материалларын формалаштыруга концептуаль якын килү предметның үзенчәлекләре һәм әлеге документның 2 пунктында күрсәтелгән документларга яраклаштырып эшләнде.

Бердәм республика тесты барышында укучыларның **лингвистик компетенциясе** (тел һәм сөйләмгә караган белеме, тел материалы белән эшләгәндә, лингвистик белемнәрне куллана алуы, өйрәнгән материалны табып, аны тикшерә белү осталыгы һәм күнекмәләре), шулай ук танып белү, торкемләү, татар теле дәресләрендә алган аналитик белем һәм күнекмәләр), **тел компетенциясе** (лексик, грамматик, стилистик, орфографик һәм пунктуацион нормаларны саклау осталыгы һәм күнекмәләре), **коммуникатив (аралашу) компетенциясе** (сөйләм эшчәнлегендә продуктив һәм рецептив күнекмәләрне үзләштерү дәрәҗәсе) тикшерелә.

Татар теленнән бердәм республика тестында тәкъдим ителгән биремнәрнең үтәлеше укучыларның белем дәрәҗәләрен һәм төп гомуми

белем бирү мәктәпләрендә уку дәверендә ирешелгән нәтиҗәләрен бәяләргә ярдәм итә.

Татар теленнән бердәм республика тесты вариантлылыкны исәпкә алып эшләнде: укучыларга тәкъдим ителгән өч вариант сочинениенең берсен сайлау мөмкинлеге бирелә.

## 4. Бердәм республика тестының төзелеше һәм эчтәлегенә аңлатма

Татар теленнән бердәм республика тесты формасы һәм катлаулылыгы ягыннан төрле 11 биремне эченә алган 3 бүлектән тора.

1 бүлек - кыска изложение (1 нче бирем).

2 бүлек - кыска җавап бирүне таләп иткән 9 бирем (2-10 нчы биремнәр).

Тестта кыска җавап бирүне таләп иткән түбәндәге төрдәге биремнәр тәкъдим ителә:

- укучы үзе формалаштырган кыска җавапны яза торган ачык типтагы биремнәр;
- тәкъдим ителгән җавап вариантларыннан берсен сайлап алып яза торган биремнәр.

3 бүлек – укылган текст нигезендә үз фикереңне белдерә алуны тикшерүгә юнәлдерелгән, киңәйтелгән җавап бирүне таләп иткән, ачык типтагы бирем (11 нче альтернатив бирем - сочинение).

*Биремнәрнең бүлекләрдә бирелеше*

*1 нче таблица*

| **Тестның бүлекләре** | **Биремнәрнең саны** | **Иң югары башлангыч балл** | **Бирем төрләре** |
|---|---|---|---|
| 1 нче бүлек | 1 (1 нче бирем) | 7 | Киңәйтелгән җавап бирүне таләп иткән |
| 2 нче бүлек | 9 (2-10 нчы биремнәр) | 9 | Кыска җавап бирүне таләп иткән биремнәр |
| 3 нче бүлек | 1 (11 нче бирем) | 9 | Киңәйтелгән җавап бирүне таләп иткән |
| 1 нче һәм 3 нче бүлекләр | | Грамоталылык һәм сөйләмнең төгәллеге өчен 10 | |
| Барлыгы: | 11 | 35 | |

**5. Үрнәк материаллары биремнәренең эчтәлеге һәм тикшерелә торган эш төрләре буенча бүленеше**

*Биремнәрнең "Татар теле" предметының төп эчтәлеге буенча бүленеше*

*2 нче таблица*

| Бүлекләрнең исеме | Биремнәр саны | Иң югары башлангыч балл | 35 иң югары башлангыч баллдан чыгып, әлеге бирем өчен куелган иң югары балл (процентларда) |
|---|---|---|---|
| Сөйләм. Тыңлау. Телдән сөйләмне дөрес аңлау. Изложение. Тыңлаган текстны язмача кыска формада бирү (кыска изложение) | 1 | 7 | 17 |
| Сөйләм. Уку. Язмача сөйләмне дөрес аңлау. | 1 | 1 | 3 |
| Лексикология һәм фразеология | 2 | 2 | 8 |
| Морфология | 2 | 2 | 8 |
| Синтаксис | 2 | 2 | 8 |
| Пунктуация | 1 | 1 | 3 |
| Татар сөйләменең сәнгатьлелеге | 1 | 1 | 3 |
| Сөйләм. Язу. Бирелгән тема һәм сөйләмнең функциональ-мәгънәви тибына туры килгән текст язу | 1 | 9 | 23 |
| Сөйләм эчтәлегенең төгәллеге һәм грамоталы булуы. | 1 нче һәм 3 нче бүлекләрдә (гомуми) | 10 | 27 |
| Барлыгы: | 11 | 35 | 100% |

Татар теленнән бердәм республика тесты биремнәре тел материалын бирү төрләре ягыннан аерыла (3 нче таблицаны кара). Укучылар текстта

бирелгән тел күренешләре белән эш итә. Алар әзер тексттан тиешле материалны табып эшли, монологик сөйләм төзи.

*Бердәм республика тестындагы тел материалы белән эш төрләре*

*3 нче таблица*

| Эш төрләре | Биремнәр саны | Иң югары башлангыч балл | 35 иң югары башлангыч баллдан чыгып, имтихандагы тел материалы белән эш төрләре өчен куелган иң югары балл (процентларда) |
|---|---|---|---|
| Изложение язу | 1 | 7 | 17 |
| Текстта бирелгән тел материалы белән эшләү | 9 | 9 | 33 |
| Сочинение язу | 1 | 9 | 23 |
| Грамоталылык | | 10 (изложение һәм сочинение язу нигезендә) | 27 |
| Барлыгы: | 11 | 35 | 100% |

**6. Биремнәренең катлаулылык дәрәҗәсе ягыннан бүленеше**

*4 нче таблица*

| Биремнәрнең катлаулылык дәрәҗәсе | Биремнәр саны | Иң югары башлангыч балл | 35 иң югары башлангыч баллдан чыгып, әлеге биремнең катлаулылыгы өчен куелган иң югары балл (процентларда) |
|---|---|---|---|
| Нигез (база) | 10 | 26 | 84 |
| Югары | 1 | 9 | 16 |
| Барлыгы: | 11 | 35 | 100% |

**7. Бердәм республика тестын үтәү** өчен, 2 сәгать 30 минут (150 минут) вакыт бирелә.

**8. Өстәмә материаллар һәм җиһазлар**

Татар теленнән үткәрелә торган бердәм республика тестында орфографик сүзлекләрдән файдаланырга рөхсәт ителә.

**9. Аерым биремнәрне һәм барлык эшне бәяләү системасы**

**1 нче бүлектәге** 1 нче бирем (кыска изложение) махсус төзелгән критерийлар буенча бәяләнә. Кыска изложение өчен иң югары балл – 7.

**2 нче бүлектәге** һәр дөрес җавап өчен укучыга 1 балл куела. Ялгыш җавап бирелсә яки җавап булмаса, 0 балл куела. Бу бүлектә дөрес җаваплар өчен укучы иң югары **9 балл** җыя ала.

**3 нче бүлектәге** бирем махсус төзелгән критерийлар буенча бәяләнә. Альтернатив бирем өчен **иң югары балл – 9.**

Изложение һәм сочинениене тикшерү нәтиҗәсе буенча укучының **грамоталылыгы** һәм язма сөйләмдәге төгәллеге өчен **10 балл** куела.

Тестның барлык биремнәрен үтәгән өчен, укучы җыярга мөмкин булган **иң югары балл – 35.**

**10. Татар теленнән үткәрелә торган бердәм республика тестын үткәрү шартлары (белгечләргә карата куела торган таләпләр)**

Татар теленнән тест үткәрелә торган бүлмәгә татар филологиясе буенча белгечләр кертелми.

**Бердәм республика тестын оештыруда андагы укучылар белән эшләмәгән педагог** кына катнаша ала. Тестны бердәм таләпләр нигезендә үткәрү аның тиешле шартларын булдыруны һәм үтәүне шушы фән буенча читтән махсус белгечләр чакырмыйча да башкарырга мөмкинлек бирә.

**Тестның тәкъдим ителә торган тәртибе** түбәндәгечә:

1. Тест материаллары салынган пакетны алгач, укучылар бирем эшлисе бланкларга имзаларын куя, аннары аларны өстәлгә тәртибе буенча җыеп куя. Эш барышында алар тиешле формада тотырыла.
2. Башта укучыларга, изложение язу өчен, текст укыла. Бу вакытта алар караламага үзләренә кирәк дип санаган сүзләрне язып бара ала. Икенче тапкыр тыңлагач, укучылар аның эчтәлеген кыскача яза. Изложение тексты аудиоязмада тыңлана.

Кыска изложениене үткәрү үрнәге:

| № | Оештыру эше | Укучылар эше | Бирелә торган вакыт |
|---|---|---|---|
| 1 | Аудиоязманы беренче кат тыңлау | Укучылар текстны тыңлыйлар, караламага кайбер сүзләрне язып баралар | 2,5 – 3 минут |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2 | Уйлану өчен бераз вакыт бирелә | Укучылар каралама белән эшлиләр | 3-4 минут |
| 3 | Аудиоязманы икенче кат тыңлау | Укучылар текстны кабат тыңлыйлар | 2,5 – 3 минут |
| 4 | Аудиоязманы туктату, изложение яза башларга һәм орфографик сүзлекләрдән файдаланырга рөхсәт бирелә | | |
| 5 | | Укучылар кыска изложение язалар | |

3. Аннан соң укучыларга, тестның икенче бүлеген үтәү өчен, текст таратыла. Алар укылган текстның эчтәлеген чагылдырган һәм лингвистик анализ ясауга бәйле биремнәрне үтиләр.

**Бердәм республика тестының барлык бүлекләрендәге биремнәрне үтәгәндә, укучыларга орфографик сүзлектән файдаланырга рөхсәт ителә.**

Киңәйтелгән җавап бирүне таләп иткән биремнәрнең дөреслеген бердәм республика тестын уздыру буенча махсус әзерлек узган татар теле белгечләре тикшерә.

## 11. Бердәм республика тестына әзерләнү өчен кайбер киңәшләр

Тестка әзерләнгәндә, укучыларга татар теленнән урта гомуми белем бирү мәктәпләренә Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән гамәлдәге дәреслекләрдән, Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы рөхсәте белән чыгарылган ярдәмлекләрдән, күрсәтмә материаллардан файдаланырга киңәш ителә.

## 12. 2015 нче елдагы бердәм республика тестының 2014 нче елда татар теленнән бердәм республика тесты уздыру өчен үрнәк материалларыннан аермасы

Эшнең төп эчтәлеге, нигездә, саклана. Кыска җавап таләп иткән 2 бүлек биремнәре текстка бәйле эшләнә. Биремнәр саны һәм эшне үтәү өчен билгеләнгән башлангыч балл үзгәрә. Тәкъдим ителгән биремнәр тоташ нумерация белән бирелә. Киңәйтелгән җавап бирүне таләп иткән, ачык типтагы 1 альтернатив бирем (11.2) өстәлә.

*Кушымта*

**2015 нче елда 9 нчы сыйныф укучыларына ТАТАР ТЕЛЕННӘН бердәм республика тесты уздыру өчен үрнәк материалларының гомумиләштерелгән планы**

*Биремнәрнең катлаулылык дәрәҗәсе: Н – нигез (база) (үтәлү вакытының 60-90%ы), Ю – югары (40% тан кимрәк вакыт эчендә үтәлә).*

| № | Тикшерелә торган эчтәлек элементлары | Тикшерелә торган эчтәлек кодлары | Тикшерелә торган күнекмәләрнең кодлары | Биремнең катлаулылыгы | Бирем өчен иң югары балл | Биремне үтәү вакыты (мин) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Төрле стиль һәм жанрдагы текстларны эшкәртү. Текстның мәгънәви һәм композицон бөтенлеге. Темага, максатка һәм аралашу ситуациясенә карап, тексттан тел чараларын сайлап алу. Төрле стильдәге текстлар төзү. Лексик, морфологик, синтаксик һәм пунктуацион нормаларны саклау. | 8.1<br>8.4<br>8.6<br>9.2<br>9.3<br>9.4 | 1.2<br>1.3<br>3.1<br>3.2<br>3.3<br>3.4<br>3.5<br>3.6<br>3.7<br>3.8<br>3.9 | Н | 7[1] | 60 |
| 2. | Сөйләм берәмлеге буларак текст. Текстның композицион һәм мәгънәви бөтенлеге. Текстка анализ. | 8.1<br>1.2 | 3.7<br>3.8 | Н | 1 | 3 |
| 3. | Лексика һәм фразеологиянең сәнгатьлелек чаралары. Сәнгатьлелек чараларына анализ. | 10.2 | 1.1 | Н | 1 | 4 |
| 4. | Мөстәкыйль сүз төркемнәре. | 4.1 | 1.1 | Н | 1 | 4 |
| 5. | Модаль сүз | 4.2 | 1.1 | Н | 1 | 3 |

[1] I һәм II нче биремнәрен тикшергәндә грамоталык һәм сөйләмнең тогәллеге изложение белән сочинение тикшерүгә нигезләнеп башкарыла һәм 10 баллга тигез.

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | төркемнәре | | | | | |
| 6. | Лексика һәм фразеология. Синонимнар | 2.3 | 1.1<br>3.8 | Н | 1 | 3 |
| 7. | Җөмлә. Җөмләнең грамматик нигезе. Ия белән хәбәр. | 5.4 | 1.1 | Н | 1 | 3 |
| 8. | Җөмлә. Кушма җөмләгә синтаксик анализ | 5.9 | 1.1 | Н | 1 | 3 |
| 9. | Пунктуация. Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре. | 5.9<br>7.3 | 1.1 | Н | 1 | 3 |
| 10. | Татар теленең тәэсирлелек чаралары | 10.1 | 1.1<br>5.1<br>8.3 | Н | 1 | 4 |
| 11. | Төрле стиль һәм жанрдагы текстларны эшкәртү һәм төзү. Текстның мәгънәви һәм композицион бөтенлеге. Темага, максатка һәм аралашу ситуациясенә карап, тексттан тел чараларын сайлап алу. Төрле стильдәге текстлар төзү. Лексик, морфологик, синтаксик һәм пунктуацион нормаларны саклау. | 7.2<br>7.3<br>8.1<br>8.2<br>8.3<br>8.4<br>8.6<br>9.2<br>9.3<br>9.4 | 2.1 2.4<br>3.2 – 3.5<br>3.7 – 3.9 | Ю | 9 | 60 |

Барлыгы **11** бирем.

Катлаулылык дәрәҗәсе буенча **10 сы** – нигез, **1се** – югары катлаулылыкта.

Максималь башлангыч балл – **35.**

Эшне үтәү өчен бирелә торган вакыт – **150 минут.**